ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2023 г. Казань № 549-45/кс-2023

«Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2023 № 57-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – өчен «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ) эчә торган суга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ өчен, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, эчә торган суга 2024-2028 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы

карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2023 № 549-45/кс-2023
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ өчен эчә торган суга 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Түбән Кама муниципаль районы | | |
| 1 | «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ | | |
| 1.1 | «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге халкына су белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтүче оешмалар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 12,50 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 12,50 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 12,50 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 13,00 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 13,00 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 13,52 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 13,52 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 14,06 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 14,06 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 14,62 |

| Т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 29,79 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 32,36 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 32,30 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 32,30 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 32,30 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 33,84 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 33,84 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 33,91 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 33,91 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 35,56 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2023 № 549-45/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Су чистарту станциясе – Түбән Кама нефть химиясе» АҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2024 | 149 945,51 | х | - | 6,38 | 0,55 |
| | | 2025 | х | 1 | - | 6,38 | 0,55 |
| | | 2026 | х | 1 | - | 6,38 | 0,55 |
| | | 2027 | х | 1 | - | 6,38 | 0,55 |
| | | 2028 | х | 1 | - | 6,38 | 0,55 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге